| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«НОВОЧЕРШИЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ЯҢА ЧЫРШЫЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның 30 октябре № 48

Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Кузайкино торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1.2023елның 18 ноябрenә Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авылы җирлеге Кузайкино торак пунктында гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнарның җыенын 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Сез 2024 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Яңа Чыршылы авыл җирлеге Кузайкино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 2000 (Ике мең) сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме:

җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү, җирлек территориясен төзекләндерүне күрсәтелгән Кагыйдәләргә ярашлы оештыру:

-Кузайкино авылы территориясендә үлән чабу,
-Үзәк урамындагы иске агачларны кисү;

Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
-Кузайкино торак пунктында үзәк урам буенча туфрак-вак таш юлларын ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Яңа Чыршылы поселогы, Заречная урамы, 25 - үзидарә администрациясе бинасы, Үзәк урам, 12а - авыл мәдәният йорты бинасы,Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Яңа Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Г.Ә. Мөхәмәтшина